| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.03.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 578** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 ноябрендәге «Үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыручы ирекле халык дружинасы халык дружиналарын бүләкләү шартлары һәм тәртибе турында» 2413 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда катнашучы халык дружиначыларын бүләкләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 ноябрендәге «Үз эшчәнлегенТатарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыручы ирекле халык дружинасы халык дружиналарын бүләкләү шартлары һәм тәртибе турында» 2413 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. 1.9 пунктта:
«5 000 сум» сүзләрен «7 000 сумга» сүзләренә алмаштырырга;
«4 000 сум» сүзләрен «6 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;
«3 000 сум» сүзләрен «5 000 сумга» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.8 пунктының икенче абзацында «3 000 сум» сүзләрен «5 000 сумга» алмаштырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районының ирекле халык дружинасы халык дружинникларына акчалата премия түләү чыгымнарын «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтевага Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетында күрсәтелгән максатларга каралган акчалар хисабына финанслауны тормышка ашырырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны «Интернет» челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Зеленодольск муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның 1.1, 1.2 п. гамәлен 2002 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В.Старостинга йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев